СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2016 елның "16" нояберennнән — № 23-37

1. Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлегенә әлеге карар белән туры китереп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2. Җир салымының салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән билгеләнә:

- шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,2%;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата 0,3%;

- торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлекләренә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

- административ һәм офис биналары, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат, физик культура һәм спорт, сәнгать, дин белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата 0,3 %.

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган җирлекләрдә авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы җирләргә карата 1,5%;

- Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

3. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымыннан азат итәргә:

- 75 яшьтән өлкәнрәк, ялгызлыкта яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар.

- ятим балалар; - стихияле бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;

- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары;

- гражданнар күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр;

- янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары һәм ирекле янгын сүндерүчеләр.

4. Салым түләүчеләр - оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла. Беренче квартал узганнан соң, 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал узгач, 15 августтан да соңга калмыйча һәм өченче квартал узганнан соң, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча,

аванс түләүләрен түләү вакытлары. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

5. Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә салым базасын киметүгә хокукны раслый торган документлар салым түләүчеләр тарафыннан салым салу объекты итеп узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча танылa торган җир кишәрлеге урнашкан урын буенча салым органына тапшырыла.

6. «Җир салымы турында» 2015 елның 11 сентябрендәге 48-100а номерлы Зирекле авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында novosheshminsk.tatarstan.ru игълан итәргә (бастырырга).

8. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Ж.Г. Гайфетдинов